ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.10.2016 Казан ш. № 10-13/кс

«Азнакай җылылык челтәрләре оешмасы» ачык акционерлар җәмгыяте өчен эчергә яраклы суга һәм су бүлүгә тарифлар билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ санлы Федераль законга, «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә җайга салынучы тарифларны исәпләп чыгару буенча Методик күрсәтмәләрне раслау турында» тарифлар буенча Федераль хезмәтнең 2013 елның 27 декабрендәге № 1746-э санлы боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Азнакай җылылык челтәрләре оешмасы» ачык акционерлар җәмгыяте өчен эчергә яраклы суга һәм су бүлүгә тарифларны әлеге карарның кушымтасы нигезендә билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар карарның үз көченә кергән көннән алып 2016 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. «Азнакай җылылык челтәрләре оешмасы» ачык акционерлар җәмгыятенә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 санлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән алып 30 календарь көннән дә соңга калмыйча халыкка җиткерелергә тиешле мәгълүматны ачарга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазифаларын башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасының
тарифлар буенча дәүләт комитетының
18.10.2016 № 10-13/кс
карарына кушымта

«Азнакай җылылык челтәрләре оешмасы» ачык акционерлар җәмгыяте өчен
эчергә яраклы суга һәм су бүлүгә тарифлар

| №<br>п/п | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне<br>һәм су бүлүне башкаручы оешма | Эчергә яраклы суга тариф<br>(бер ставкалы),<br>сум/куб.метр | Су бүлүгә тариф<br>(бер ставкалы),<br>сум/куб.метр |
|---|---|---|---|
| | | Карарның үз көченә кергән көннән алып 2016 елның 31 декабренә кадәр | Карарның үз көченә кергән көннән алып 2016 елның 31 декабренә кадәр |
| | Сарман муниципаль районы | | |
| 1 | «Азнакай җылылык челтәрләре оешмасы» ачык акционерлар җәмгыяте | | |
| 1.2 | Сарман авыл җирлеге кулланучылары | | |
| 1.2.1 | Халык (тарифлар НДС белән күрсәтелгән)* | 26,11 | 33,41 |
| 1.2.2 | Башка кулланучылар (тарифлар НДСтан тыш күрсәтелгән) | 22,13 | 28,31 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 маддәсе 6 пунктын гамәлгә ашыру максатыннан чыгып бүлеп бирелә

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты, Тарифлар буенча карарларны
кабул итү, оештыру һәм җайга салу бүлеге